**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 июнь № 403

г. Казань

Капиталь ремонт фонды формалашу юлы үзгәргәндә, капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында, счетларында формалашкан очракта төбәк операторы тарафыннан яки капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашкан очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яки) төбәк операторына капиталь ремонт фонды формалашу белән бәйле бөтен булган документларны һәм мәгълүматны бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 173 статьясындагы 7 өлеш, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешнең 13.3 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Капиталь ремонт фонды формалашу юлы үзгәргәндә, капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында, счетларында формалашкан очракта төбәк операторы тарафыннан яки капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашкан очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яки) төбәк операторына капиталь ремонт фонды формалашу белән бәйле бөтен булган документларны һәм мәгълүматны бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 15 июнь, 403 нче
карары белән расланды

Капиталь ремонт фонды формалашу юлы үзгәргәндә, капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында, счетларында формалашкан очракта төбәк операторы тарафыннан яки капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашкан очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яки) төбәк операторына капиталь ремонт фонды формалашу белән бәйле бөтен булган документларны һәм мәгълүматны бирү тәртибе

1. Бу Тәртип, капиталь ремонт фонды формалашу юлы үзгәргәндә, күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында, счетларында формалашкан очракта төбәк операторы тарафыннан яки күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашкан очракта махсус счет хуҗасы тарафыннан тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яки) төбәк операторына капиталь ремонт фонды формалашу белән бәйле бөтен булган документларны һәм мәгълүматны бирү механизмын билгели (алга таба – Тәртип).

2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) төбәк операторы – күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган махсуслаштырылган коммерциячел булмаган оешма;

2) махсус счет хуҗасы – кредит оешмасында ачылган һәм күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә акча күчерү өчен каралган махсус счет аның исеменә ачылган зат.

3. Капиталь ремонт фонды формалашу юлы үзгәргәндә, капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында, счетларында формалашкан очракта төбәк операторы яки капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашкан очракта махсус счет хуҗасы (күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан махсус счет хуҗасы буларак төбәк операторы сайланган очраклардан тыш) тиешенчә махсус счет хуҗасына һәм (яки) төбәк операторына капиталь ремонт фонды формалашу белән бәйле бөтен булган документларын һәм мәгълүматны бирә:

1) Россия Федерациясе Торак кодексының 173 статьясындагы 10 өлеш, 175 статьясындагы 9 өлеш, 189 статьясындагы 7 өлеш нигезендә капиталь ремонт фонды формалашу һәм аннан файдалану мәсьәләләре буенча, шул исәптән капиталь ремонт фонды формалашу юлы үзгәрү турында күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышлары карарлары һәм (яки) капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында формалашу хакында җирле үзидарә органы карары күчермәсе;

2) күпфатирлы йортка техник документлар күчермәсе (булган очракта);

3) күпфатирлы йорттагы урынның мәйданы һәм милекчесе хакында белешмәләрне үз эченә алган әлеге йорттагы һәр урын турында мәгълүмат (булган очракта);

4) күпфатирлы йорттагы һәр урын милекчесенә кагылышлы мәгълүмат: капиталь ремонт өчен исәпләнгән һәм түләнгән кертемнәр һәм өстәмә түләүләр күләме турында, капиталь ремонт фонды акчасы керү һәм аны алу буенча операцияләр хакында, капиталь ремонт өчен кертемнәрне түләү буенча бурыч күләме һәм әлеге бурычның барлыкка килү чоры турында (булган очракта);

5) күпфатирлы йорттагы урын милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау өчен кертемнәрне түләү буенча бурычны алу турында мәгълүмат (шул исәптән суд карарлары, башкару производствосы белән бәйле документлар (булган очракта);

6) күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрне һәм (яки) эшләрне финанслау максатларында җәлеп ителгән кредитлар, заемнар турында мәгълүмат, шул исәптән алар җәлеп ителгән процент ставкасын күрсәтеп, шулай ук әлеге кредитларны, заемнарны түләү хакында мәгълүмат (булган очракта);

7) күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауга юнәлдерелгән акча күләме, шул исәптән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләүгә бирелгән соңрак түләү күләме турында мәгълүмат (булган очракта);

8) күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау белән бәйле документлар күчермәләре (шул исәптән хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга шартнамәләр, күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләр актлары, сметалар, проектлар, бәяләмәләр) (булган очракта);

9) күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча күрсәтелгән хезмәтләр һәм (яки) башкарылган эшләр өчен түләү буенча булган бурыч һәм аның күләме хакында мәгълүмат (булган очракта);

10) махсус счетта калган акча һәм аның күләме турында һәм махсус счет буенча барлык операцияләр хакында мәгълүмат (капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашудан туктаган очракта);

11) әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән затларның вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

12) капиталь ремонт фонды формалашу һәм аның эшчәнлеге белән бәйле башка документлар (булган очракта).

4. Россия Федерациясе Торак кодексының 173 статьясындагы 10 өлеш, 175 статьясындагы 9 өлеш, 189 статьясындагы 7 өлеш нигезендә әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында каралган документлар һәм мәгълүмат капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында формалашудан туктау һәм капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашуы турындагы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары яки капиталь ремонт фонды махсус счетта формалашудан туктау һәм капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында формалашуы хакындагы күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары һәм (яки) капиталь ремонт фонды төбәк операторы счетында формалашу турында җирле үзидарә органы карары үз көченә кергән көннән соң

календарь көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә кәгазьдә һәм (яки) электрон рәвештә бирелергә тиеш.

5. Әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында каралган документлар һәм мәгълүматны тапшыру төбәк операторының һәм махсус счет хуҗасының вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланырга тиешле кабул итү-тапшыру акты белән рәсмиләштерелә.

Акт үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш: аны төзү көне һәм вакыты, тапшырыла торган документлар исеме һәм реквизитлары, актка кул куйган вәкаләтле затлар хакында мәгълүматлар (фамилияләре, инициаллары, вазыйфалары, әлеге затларның вәкаләтләрен раслый торган документлар төрләре һәм реквизитлары).

Акт ике нөсхәдә рәсмиләштерелә: берсе – махсус счет хуҗасы өчен, икенчесе – төбәк операторы өчен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын тулысынча тормышка ашырганчы саклана.

Тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларны тапшырган тиешле вәкаләтле зат өстендә була.

F:\KARAR\2016\403.docx